**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 октябрендәге 4496 номерлы карары**

**Җәйге һәм кышкы чорларда Казан шәһәре юлларын һәм**
**туристлык маршрутларын карап тотуга**
**финанс чыгымнары нормативлары турында**

2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы федераль закон һәм Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2012 елның 16 ноябрендәге 402 номерлы «Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр классификациясен раслау турында»гы әмере нигезендә **карар бирәм**:

1. Җәйге һәм кышкы чорларда Казан шәһәре юлларын һәм туристлык маршрутларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативларын әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Казан шәһәре Башкарма комитеты районнары администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов), Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) җәйге һәм кышкы чорларда Казан шәһәре юлларын һәм туристлык маршрутларын норматив буенча карап тотуны тәэмин итүне контрольдә тотарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 2522 номерлы «Җәйге һәм кышкы чорларда Казан шәһәре юлларын һәм

туристлык маршрутларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативлары турында»гы һәм 2024 елның 22 апрелендәге 1601 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 1 октябрендәге 2522 номерлы “Җәйге һәм кышкы чорларда Казан шәһәре юлларын һәм туристлык маршрутларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативлары турында”гы карарына үзгәреш кертү хакында»гы карарларын 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.В.Куляжевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4496 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Җәйге һәм кышкы чорларда Казан шәһәре юлларын һәм туристлык маршрутларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативлары**

(сум)

| **Объект атамасы** | **Җәйге чорда финанс чыгымнары нормативы (көненә кв.м өчен)** | **Кышкы чорда финанс чыгымнары нормативы (көненә кв.м өчен)** |
|---|---|---|
| Юлларны карап тоту | | |
| 1 категория | 0,45 | 0,90 |
| 2 категория | 0,26 | 0,52 |
| 3 категория | 0,06 | 0,27 |
| Квартал эчендәге юллар | 0,21 | 0,42 |
| Туристлык маршрутларын карап тоту (җәяүлеләр урамнары) | 1,03 | 2,18 |
| Туристлык маршрутларын карап тоту | 0,54 | 1,01 |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 28 октябрендәге
4496 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең туристлык маршрутлары исемлеге**

| **№ т/б** | **Маршрут** | **Урамнар** |
|---|---|---|
| 1 | Тукай мәйданы – Бауман урамы – М.Җәлил урамы – Кремль урамы – Беренче Май мәйданы | Бауман урамы (җәяүлеләр урамы) |
| | | М.Җәлил урамы |
| | | М.Җәлил урамындагы баскыч |
| | | Кремль урамы |
| | | Беренче Май мәйданы |
| 2 | Кремль урамы – Казан Кремле – Батурин урамы – Большая Красная урамы – Япеев урамы – К.Маркс урамы – Лобачевский урамы – Большая Красная урамы – Ирек мәйданы – Пушкин урамы | Кремль урамы |
| | | Батурин урамы |
| | | Большая Красная урамы |
| | | Япеев урамы |
| | | К.Маркс урамы |
| | | Лобачевский урамы |
| | | Ирек мәйданы |
| | | Пушкин урамы |
| 3 | Кремль урамы – Казан Кремле – Батурин урамы – Кремль яр буе урамы – Милли китапханә – Ирек мәйданы | Кремль урамы |
| | | Батурин урамы |
| | | Кремль яр буе урамы |
| | | Касаткин урамы |
| | | Театр урамы |
| | | Ирек мәйданы |
| 4 | Казан (Идел буе) федераль университеты (Лобачевский скверы) – Кремль урамы – Лобачевский урамы – Ленин бакчасы – Пушкин урамы – Горький урамы – Мөштәри урамы – К.Маркс урамы – Жуковский урамы – Милли китапханә | Кремль урамы |
| | | Лобачевский урамы |
| | | Пушкин урамы |
| | | Горький урамы |
| | | Мөштәри урамы |
| | | К.Маркс урамы |
| | | Жуковский урамы |
| | | Адамюк урамы |
| | | Малая Красная урамы |
| 5 | Тукай мәйданы – Петербург урамы – Ульянов-Ленин урамы – Катанов тыкрыгы – Ульянов-Ленин урамы | Петербург урамы (җәяүлеләр урамы) |
| | | Петербург урамы |
| | | Ульянов-Ленин урамы |
| | | Маяковский урамы |
| | | Катанов тыкрыгы |
| | | Бутлеров урамы |

| № т/б | Маршрут | Урамнар |
|---|---|---|
| 6 | Г.Камал исемендәге театр каршындагы мәйдан – Татарстан урамы – Ш.Мәрҗани урамы – З.Солтан урамы – К.Насыйри урамы – Күнче урамы – Сафьян урамы – Г.Тукай урамы – Париж Коммунасы урамы – К.Насыйри музее – Париж Коммунасы урамы – Мәскәү урамы – Г.Камал исемендәге театр каршындагы мәйдан. Иске Татар бистәсе буенча маршрутлар | Татарстан урамы |
| | | Ш.Мәрҗани урамы |
| | | З.Солтан урамы |
| | | К.Насыйри урамы (җәяүлеләр урамы) |
| | | Күнче урамы |
| | | Сафьян урамы |
| | | Г.Тукай урамы |
| | | Париж Коммунасы урамы |
| | | Мәскәү урамы |
| 7 | Университет шәһәрчеге | Кремль урамы |
| | | Профессор Нужин урамы |
| | | Пушкин урамы |
| | | Уң як Болак урамы |
| | | Астрономия урамы |
| | | Университет урамы |
| 8 | Иске Татар бистәсе маршрутлары | К.Насыйри урамы (җәяүлеләр урамы) |
| | | Күнче урамы |
| | | С.Садыйкова урамы |
| | | Г.Тукай урамы |
| | | Ф.Кәрим урамы |
| | | Фәткуллин урамы |
| | | Ш.Мәрҗани урамы |
| | | Сул як Болак урамы |
| | | Г.Камал урамы |
| | | Мәскәү урамы |
| | | Татарстан урамы |
| | | Нариманов урамы |
| 9 | Чистай урамы | Чистай урамы |
| 10 | С.Хәким урамы (борылыш бөҗрасын, җирле юлларны һәм муниципаль парковкаларны кертеп) | С.Хәким урамы |
| 11 | Ф.Әмирхан урамы («Миллениум» күпере астындагы борылыш юлын һәм туннельләрне кертеп, «Миллениум» күпереннән Четаев урамына кадәр) | Ф.Әмирхан урамы |

---